СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

с. Верхний Услон

01.02.2016 №7-60

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы проекты турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль Законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының 14.11.2006 елның 9-109 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы Советы

Карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары һәм Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тәкъдим иткән Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм аның өстендә эшне тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып дәвам итәргә (1 нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Уставы проекты буенча килгән тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

- Никитина Людмила Николаевна – эшче төркем рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе;

- Пичугина Надежда Валерьевна – эшче төркем секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Советының юридик бүлеге начальнигы;

Эшче төркем әгъзалары:

- Козина Светлана Анатольевна – Югары Ослан муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе;

- Хурматуллина Лилия Ильфаровна – Югары Ослан муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисе;

- Коткова Лидия Ивановна – Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге башлыгы, район муниципаль берәмлекләр башлыклары Советы Рәисе;

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы проектын тикшерүдә гражданнарның катнашу тәртибен расларга (3 нче кушымта).

5. Югары Ослан муниципаль районы Уставы проекты буенча ачык тыңлауларны 2016 елның 19 февралендә 10.00 сәгатьтә Югары Ослан муниципаль районы Советының утырышлар залында, Югары Ослан авылы Чехов урамы, 18 йорт адресы буенча уздырырга.

6. Эшче төркемгә Югары Ослан муниципаль районы халкының килгән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Советына карауга кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,<br>
Югары Ослан муниципаль районы<br>
Башлыгы М.Г. Зиатдинов